| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20.12.2024 г.Казань № 718-201/кс-2024

Зеленодольск муниципаль районының «Васильевский» шифаханәсе һөнәр берлекләре дәвалау-профилактика хосусый учреждениесе өчен кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасындагы кайнар суга 2025 елга тарифлар билгеләү турында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендәге тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 20.12.2024 ел, №37-ПР утырыш беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Әлеге карар кушымтасына ярашлы рәвештә Зеленодольск муниципаль районының «Васильевский» шифаханәсе һөнәр берлекләре дәвалау-профилактика хосусый учреждениесе өчен кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасындагы кайнар суга календарь буенча бүленгән тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2025 елның 1 гыйнварыннан 2025 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Кайнар су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Васильевский» шифаханәсе һөнәр берлекләре дәвалау-профилактика хосусый учреждениесенә иркле файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең

2023 елның 26 гыйнварындагы 108 номерлы карары белән расланган Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 көннән соңга калмыйча ачарга.

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы Л.В.Хәбибуллина

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
20.12.2024 № 718-201/кс-2024
карарына кушымта

Кайнар су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Васильево» шифаханәсе һөнәр берлекләре дәвалау-профилактика хосусый учреждениесе тарафыннан кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасындагы кайнар суга 2025 елга календарь буенча бүленгән тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлек исеме, кайнар су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасындагы кайнар суга тариф (бер компонентлы), сум/куб.м | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | кайнар су белән тәэмин итүнең үзәкләштерелгән системасы | | | | | | | |
| | | изоляцияләнгән торбалар белән | | изоляцияләнмәгән торбалар белән | | изоляцияләнгән торбалар белән | | изоляцияләнмәгән торбалар белән | |
| | | сөлге киптергечләр | | сөлге киптергечләр | | сөлге киптергечләр | | сөлге киптергечләр | |
| | | әйе | юк | әйе | юк | әйе | юк | әйе | юк |
| | | 01.01.2025 башлап 30.06.2025 кадәр | | | | 01.07.2025 башлап 31.12.2025 кадәр | | | |
| | Зеленодольск муниципаль районы | | | | | | | | |
| 1 | «Васильево» санаторие профсоюзларының дәвалау-профилактика шәхси учреждениесе | | | | | | | | |
| 1.1 | халык (тарифлар НДС белән күрсәтелгән)* | 182,03 | 170,41 | 195,97 | 183,89 | 209,45 | 196,18 | 225,38 | 211,57 |
| 1.2 | башка кулланучылар (тарифлар НДС исәбеннән башка күрсәтелгән) | 151,69 | 142,01 | 163,31 | 153,24 | 174,54 | 163,48 | 187,82 | 176,31 |

* Россия Федерациясе Салым кодексының 168 статьясының 6 пунктын үтәү максатларында аерып чыгарыла.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф карарларын кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге